ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2023 г. Заинск № 244

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның тукlануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясе Коралллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган РФ гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында" 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 14 декабрендәге 1213 номерлы карары нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 27 февралендәге 124 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына (08.07.2022 ел, № 337; 23.05.2022 ел, № 249; 03.10.2022 ел, № 506; 07.12.2022 ел, № 620 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 1 нче кушымтада үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 2.1.6. пунктында: «өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергән, яки Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә

ирекле ярдәм турында контракт төзегән, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булган гражданнар» сүзләрен «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнар» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе 5 нче бүлеге 5.2 пунктының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «-Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның балалары»;

**1.3.** Түләүсез туклану белән тәэмин итү тәртибе 5 нче бүлеге 5.2 пунктының унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: **«-Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) югарыда күрсәтелгән категориядәге гражданнарның балалары:**

- законлы вәкилдән язмача гариза;
- хәрби комиссариаттан белешмә, яки эш урыныннан белешмә».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2023 елның 01 апрельдән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сәфәргалиев
3-27-42